# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Татарстан Республикасында юллар фонды турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

"Татарстан Республикасында юллар фонды турында" Татарстан Республикасының 1991 елның 26 декабрендәге 1368-XII номерлы Законына (Татарстан Республикасы Югары Советы законнар җыелмасы, 1992, N 3; Татарстан Республикасы Югары Советы законнар җыелмасы, 1993, N3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 3 статьяның 1 пунктыннан түбәндәге сүзләрне төшереп калдырырга:

"гражданнарга шәхси файдалануга сатылачак җиңел автомобильләр акцизлары".

2. 5 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Автомобиль юлларыннан файдаланучыларга салым ставкасы сатылган продукция, башкарылган эш һәм күрсәтелгән хезмәтләр хакының 1,2 проценты күләмендә билгеләнә, ә әзерләүче, сәүдә итүче (шул исәптән күпләп сәүдә итүче оешмалар) һәм тәэминат-сәүдә оешмаларына салым ставкасы әйләнешнең 0,2 проценты күләмендә билгеләнә".

5 статьяның 3 пунктыннан түбәндәге сүзләрне төшереп кал-

216



дырырга:

"Колхозлар, совхозлар, крестьян (фермер) хуҗалыклары һәм аларның берләшмәләре, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү белән шөгыльләнүче акционер һәм башка предприятиеләр, шушы продукцияне сатудан килгән керемнәрнең гомуми суммадагы чагыштырма аурлыгы 70 һәм аннан да күбрәк процент тәшкил итсә;

гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын карап торучы предприятиеләр".

3. 6 статьяның 1 пунктын түбәндәгечә бәян итәргә:

"1. Милек рәвешләренә һәм кайсы ведомствога буйсынуларына карамастан, предприятиеләр, берләшмәләр, учреждениеләр һәм оешмалар, чит илләрнең хокукый затлары, шулай ук түбәндәге транспорт чаралары: автомобильләре, мотоцикллары, мотороллерлары, автобуслары һәм үзйөрешле башка машиналары һәм пневмойөрешле башка механизмнары булган гражданнар һәр ат көченнән салым түләү көненә гамәлдә булган айлык минималь хезмәт хакына карата түбәндәге күләмнәрдә транспорт чаралары булганнарга салынучы салым түлиләр:

| Салым салынучы объектлар атамалары | Еллык салым күләме, %ларда, салым буенча түләүләрне башкару көненә гамәлдә булган айлык минималь хезмәт хакыннан |
| --- | --- |
| 1 | 2 |
| Двигателенең куәте 100 ат көченә кадәр (73,55 кВт) булган җиңел автомобильләр | 2 |
| физик затлардан | 1 |
| 100 ат көченнән күбрәк (73,55 кВт дан артык) | 3 |
| физик затлардан | 1,5 |
| мотоцикллар һәм мотороллерлар | 0,6 |
| физик затлардан | 0,3 |
| йөк автомобильләре һәм тракторлар | 4 |
| автобуслар | 4 |

башка үзйөрешле машиналар һәм пневмо-
йөрешле механизмнар (ашлык җыючы һәм
башка махсус авыл хуҗалыгы комбайн-
нарыннан гайре) 4

---

4. 7 статьядагы 4 пунктның түбәндәге абзацын:

"колхозлар, совхозлар, крестьян (фермер) хуҗалыклары һәм аларның берләшмәләре һәм авыл хуҗалыгы продукцияләрен җитештерү белән шөгыльләнүче башка предприятиеләр, шушы продукцияне сатудан килгән керемнәрнең гомуми суммадагы чагыштырма зурлыгы 70 һәм . аннан да күбрәк процент тәшкил итсә, һәм авыл хуҗалыгына хезмәт күрсәтүче предприятиеләр, оешмалар: "Татсельхозтехника", "Татсельхозхимия", "Татагропромэнерго" берләшмәләре"

"колхозлар, совхозлар, крестьян (фермер) хуҗалыклары һәм аларның берләшмәләре һәм авыл хуҗалыгы продукцияләрен җитештерү белән шөгыльләнүче башка предприятиеләр, шушы продукцияне сатудан килгән керемнәрнең гомуми суммадагы чагыштырма зурлыгы 70 һәм аннан да күбрәк процент тәшкил итсә" дип бәян итәргә.

5. 8 статьяны төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш.Шәймиев

Казан шәһәре,
1994 елның 8 феврале
N 2075-XII